
# Галимов Ибраһим Миндар улы истәлегенә көрәш буенча Бөтенроссия ярышлары

Менделеевск шәһәрендә 10-13 ноябрьдә якташыбыз, 30 елдан артык “Кама” колхозы рәисе булып эшләгән Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Ибраһим Миндар улы Галимов һәм Татарстанның атказанган физик культура хезмәткәре Минхалит Гәрәй ул Гилманов истәлегенә багышланган көрәш буенча 7-нче Бөтенроссия ярышлары булып узды. Ярышларда Мәскәүдән, Түбән Новгородтан, Татарстаннан спортчылыр катнашты. Бу бәйгенең нинди югары дәрәҗәдә икәнен спортчылар арасында хәтта Россиянең атказанган спорт мастерлары булуы күрсәтә.

Ибраһим Миндар улы үзе дә яшь чагыннан ук спорт белән ныклап мавыга, студент елларында көрәш буенча СССРның спорт мастерлыгына кандидат нормативын үти. Аның тормыш юлы, авылыбызда калдырган эзләре турында түбәндә материал да китерелгән. Хәзер  инде ул безнең арадан китсә дә, аның исеме ел саен бөтенроссия дәрәҗәсендәге ярышларда яңгырый. Халык дөрес әйтә: яхшылык җирдә ятмый дип...


10-13
ноября
2023
МЕНДЕЛЕЕВСК
МИНСПОРТ
ВСЕРОССИЙСКИЕ
СОРЕВНОВАНИЯ ПО
БОРЬБЕ НА ПОЯСАХ
памяти
Заслуженного работника сельского хозяйства
Ибрагима Галимова
Заслуженного работника физической культуры
Минхалита Гильманова

*Президент*
*Всероссийской федерации*
*борьбы на поясах*



**РАМАЗАНОВ**
**Рушан Ринатович**

***Уважаемый оргкомитет,***
***участники соревнований, зрители!***

Приветствую Вас на Всероссийских соревнованиях по борьбе на поясах памяти Заслуженного работника сельского хозяйства Галимова Ибрагима Миндаровича и Заслуженного работника физической культуры Гильманова Минхалита Гареевича!

Хотелось бы отметить, что борьба на поясах успешно развивается и с каждым годом завоевывает все больше поклонников в Татарстане, России и за рубежом. Уверен, что и данные соревнования станут большим спортивным праздником для жителей и гостей города Менделеевска, а теплая атмосфера будет способствовать сближению молодежи разных регионов и популяризации здорового образа жизни.

Желаю всем праздничного настроения, а участникам соревнований – честной, справедливой борьбы!





*Глава Менделеевского муниципального района Республики Татарстан*

**БЕЛЯЕВ**
**Радмир Ильдарович**

***Уважаемые спортсмены, тренеры, судьи, гости!***

Рад приветствовать всех на замечательном спортивном празднике – Всероссийских соревнованиях по борьбе на поясах памяти Заслуженного работника сельского хозяйства Галимова Ибрагима Миндаровича и Заслуженного работника физической культуры Гильманова Минхалита Гареевича. Данные соревнования в седьмой раз проводятся в городе Менделеевске и это яркое событие для всех, особенно для приверженцев этого вида спорта.

Желаю всем участникам соревнований крепкого спортивного здоровья и честной борьбы. Пусть победит сильнейший!



# Ибраһим ГАЛИМОВ



Ибраһим Миндар улы Галимов 1954 елның 6 декабрендә Чирмешән районының Яңа Кади авылында дөньяга килә.

1974 елда Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына укырга керә: Яшьтән үк атаклы тренер Мәгас абый Сәхәбетдинов белән таныш булганга, ул биредә Әсгать абый Шәйхетдинов белән җиңел генә уртак тел табып, ирекле көрәш серләренә өйрәнә башлый. Шулай ук Хәбир Сабир улы Хәбибуллин белән танышып, соңрак иң якын, аерылмас дуслар булып китәләр. Ибраһим спорт белән бик бирелеп мавыкканга күрә, тиз арада институт чемпионы була. Аннан соң Татарстан, Россия күләмендәге ярышларда призлы урыннар алып спорт мастерлыгына кандидат нормасын үти. Күп тапкырлар авыл, район сабантуйларында батыр кала.

1979 елда институтны уңышлы тәмамлап , ул үзенең хезмәт биографиясен Менделеевск районының Псәй авылында агроном булып башлый.

Ибраһим Галимовны 1983 елның июнендә Менделеевск районының Бәзәкә авылында «Кама» колхозы рәисе итеп  сайлыйлар. Шул көннән башлап, ул белемен, көчен, тырышлыгын авыл хуҗалыгын күтәрүгә, үз кул астындагыларның тормышын җиңеләйтүгә багышлады. Бик тиздән ул моңа ирешә дә: искиткеч осталыгы, сәләте, бетмәс-төкәнмәс ихтыяр көче белән яшь рәис авылны яңартты, матурайтты, кешеләрен үз итте, алар белән уртак телне тиз тапты, җиң сызганып җитәкчелек эшенә кереште. Аңа ул вакытта 28 яшь иде. Яңа балалар бакчасы, ике катлы колхоз идарәсе, стадион, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга күркәм обелиск, ферма биналары төзелде. Сабантуй үткәрү өчен уңайлы урын булдырды, андагы күп ярышларның гадел судьясы да үзе иде.

Бик күп тырышлык, көч куеп 1989 елда мәчет төзеттерде һәм аның ишекләрен ачты, авыл өстендә азан тавышы яңгырады. Кечкенәдән ике улын җитәкләп җомга намазларын калдырмады. Ибраһим Миндар улы





динебезне хөрмәтләүче, аның кануннары буенча яшәүче затка әверелде. Авыл яшьләре белән дә тыгыз элемтәдә яшәде, авыл клубының һәрчак гөрләп эшләп баруын теләде. Үзе бик җиңел, оста бии иде, халык аны бик яратты. Үз авылында гына түгел, күрше авылларда һәм районда спектакльләр куюны оештырды, аларда үзе дә бик теләп уйнады. Ул тормышны яратты, яшәүнең тәмен, рәхәтен белеп яшәде.

Ә спорт дигәндә Ибраһим Галимов җанын бирергә әзер торды. Яшьләр белән рәхәтләнеп волейбол уйнады, чаңгыда йөгерде, күп ярышларның гадел хөкемдары сыйфатында катнашты. Спорт фанаты буларак, 2014 елда Сочида үткәрелгән кышкы Олимпиадага ул кызы Ләйсән белән бергә барып кайтты. Бу уеннарны өйдә, диванда утырып кына карый алмый иде шул ул. Аңа ярышларның нәкъ үзәгендә булу зарур иде. Уйлап карасаң, колхоз рәисенең бу гамәлләрдән тыш, төп вазифалары да аз түгел. Кырчылык, терлекчелек тармагында бихисап эшләре җәйрәп ята, борчу-мәшәкатьләре дә баштан ашкан. Ул көнозын кыр-басуларда булды. Озаклап яуган яки бер тамчы да төшмәгән яңгырлар өчен борчылды, янды-көйде, үз-үзенә урын таба алмады. Терлекчелектә, кырчылыкта проблемалар күп иде, ләкин белгечләр белән берлектә эшне җайга салу юлларын эзләде. Ничек кенә булмасын, хуҗалык хезмәтчәннәре авырлыкларны җиңеп, чәчәсен чәчтеләр, җыясын җыйдылар. Юкка түгел, һәр елны район сабантуенда «Кама» колхозы вәкилләре бәйрәм флагын күтәрүче һәм кыр батырлары парадының алдагы сафында баручылар булды. Болар барысы да хуҗалык җитәкчесенең алга куйган максатлары дөрес икәнен күрсәтүче, һәр эшне дә үз вакытында, сыйфатлы һәм намус белән башкаруы нәтиҗәләре.

Ибраһим Галимов озак еллар район Советы депутаты итеп сайланды, районда лидер, әйдәп баручы җитәкче булды. 1991 елның башыннан алып сентябрь аена хәтле Менделеевск районының партия оешмасының беренче секретаре вазифаларын да башкарды.

Ул масая, мактана белмәде, беркайчан дан-шөһрәт артыннан кумады. «Татарстанның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән исем дә аңа 2014 елда гына бирелде. Менә шушындый сыйфатлар аңа кайдан килгән? Әлбәттә, аның әти-әнисе, укытучылары һәм остазлары туры, дөрес юл күрсәткәннәр. Ул 32 ел дәвамында колхозны таркатмады, авылны бетермәде. Ибраһим Миндар улы тормышның ямен белеп яшәде, яшен булып яшьнәде. Билгеле, моңа аның йөрәге чыдамады — Ибарһим чабып барган ат егылгандай 2015 елның 9 мартында бакыйлыкка күчте. Әмма аны белгәннәр күңелендә ул озак вакытлар яшәр әле, чөнки үзеннән соң үрнәк гаиләсе, балалары, изге гамәлләре калды.




Ярыш мизгелләре



И.М.Галимовның туганнары. Утырганнар сулдан уңга: энесе Исмәгыйл, абыйсы Фоат, хатыны Сәрия Галимовлар. Басканнар: энесе Әнәс, кызы Ләйсән.